СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 16-21 от « 26 » апреля 2023 г.

2023 елда Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, 2022 елның 04 ноябрендәге 424-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча җирле үзидарә органнарында һәм Мамадыш муниципаль районының муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дип билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Советының регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Башлык,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов

000037